**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5615**
**28.10.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 номерлы карары белән расланган хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу килешүе буенча гражданнарга торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3272 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6595 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3047 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу килешүе буенча гражданнарга торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктның 5 пунктчасында «Яшәү урыныннан белешмә» сүзләрен «Торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслаучы мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга;»;

2) 2.6 пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алына:

- аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (гаиләнең һәр әгъзасына)»;

3) 3.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына

хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә (гаиләнең һәр әгъзасына) бирү турында электрон рәвештә запрос җибәрә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов